**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Манзарас авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№37**

**«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Люга авылы, Центральная урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә

2. 2020 елның 27 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Люга авылы, Центральная урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2020 елның 27 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Люга авылы, Центральная урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе (территориаль, вакытлы яки башка билге буенча) муниципаль берәмлек Башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 яки күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр яисә ялгыз аналар, 80 яштәге һәм аннан өлкәнрәк яштәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Өлге авылының урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү;
- Өлге авылында урамнарга энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өлге авылы территориясен төзекләндерү (яшелләндерү, агачларны кисү);
- насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Өлге авылының Үзәк урамын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өлге авылы зиратын коймалау, проект-смета документларын эшләү;
- Өлге авылының балалар мәйданчыгын коймалау, проект-смета документларын эшләү?»